# Татар халкын күтәргән немецлар

Татар халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, этнографиясен һәм авыз иҗатын махсус өйрәнгән башка милләт вәкилләре дә бар, шулар арасыннан немецларны аерып күрсәтзсе килә. 18 гасырда шундый фидакарь җаннарныћ берсе тарихчы Герард Фридрих Миллер булса /1705-1783/, 18-19 гасырларда медицина профессоры Фукс Карл Федорович /1776-1846/ Казан татарларының тарихын һәм этнографиясен өйрәнүгә гомерен багышлаган, 19-20 гасырларда исә төрки телләр белгече Фридрих Вильгельм /Василий Васильевич/ Радлов /1837-1918/ Себер киңлекләрендә татар халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыеп йөргән, тиңдәшсез китаплар язып калдырган. Моннан тыш та немец тарихчы-телчеләре татарларның үткәненә, тел үзенчәлекләре һәм мәдәниятенә һәрдаим игътибар итеп килгәннәр һәм яхшы фикерләр язып калдырганнар.

Татар халкының тарихын өйрәнгән һәм аны күтәргән немец галимнәрнең исемлеген юкка гына Герард Миллердан башламадык, чөнки аны "Себер тарихының атасы", дип әйтергә мөмкин. Урысча Федор Иванович, дип атап йөртелгән Герард Миллер Россиягә 20 яшендђ килә һәм гомеренең ахырына кадәр биредә яши, фәнгә хезмәт итә. Дәресен әйтергә кирәк, Россиядә академик тарих фәненең башында немецлар тора, тарихны системага салып өйрәнү дә алардан башланган, чөнки аларга кадәр урыс тарихы чиркәү елъязмалары нигезендә генә формалашкан була. Немецлар урыс тарихчыларын архив белешмәләре нигезендә эшләргә өйрәтәләр, алар шулай ук җирле халыкларның тарихларын һәм тормышларын өйрәнүгә дә зур игътибар бирәләр.

Герард Миллер да үзенеә тарихчылык миссиясен җирле халыклар тормышын өйрәнүдән башлый, 1733-1743 елларда ул Себерне өйрәнү экспедициясендә катнаша, шуның нәтиҗәсендә, соңыннан "Описание Сибирского царства" дигән титаник хезмәтен яза /1750/. Дөрес, соңыннан аның бу хезмәтен урыслар "История Сибири" дип тәрҗемә итеп чыгаралар, чөнки Миллерча, Себер патшалыгы, дип язсаң, аның аерым мөстәкыйль татар дәүләте булуын искә төшергә туры килер иде, ә урыс тарихчылары моны искә төшерергә яратмыйлар. Миллер исә Себернең кайчандыр татар дәүләте булуын, ә аның төп халкы татарлар икәнлеген ачыктан-ачык әйтә, шуны исбатлау өчен ул Урал тауларыннан Тын океан ярларына кадәр барып җитә, җирле халыклар белән очраша, аларның тарихын, этнографиясен, авыз иҗатын, нәсел

шәҗәрәләрен өйрәнә, шулай ук чиркәү һәм монастырь архивларындагы урыс елъязмаларын җентекләп тикшерә.

“Главнейшим народом Сибири являются татары, которые живут в южных местностях по рекам Тоболу, Иртышу, Оби, Томи, Енисею и лежащих между ними степях, - дип яза ул соңыннан. - Хотя история татарского народа относит начало его к таким далеким временам, какими не может похвалиться ни один европейских народов, но нужно признать, что древнейшие события ее основываются на недостоверных и баснославных рассказах, ходивших в народе, и что настоящая достоверная история татар начинается только со времен великого Чингиз-хана, который в начале XIII столетия после Р.Х. народ, пребывавший до тех пор во тьме, вывел на свет.” /Миллер Г.Ф. История Сибири. Т. 1. – Москва, 1999, стр.166./

Әмма Россия Фәннәр Академиясенә Миллерның татар тарихын күтәрүе һич кирәк булмый, алар аннан урыс халкының бөек тарихын язуын көтәләр һәм галимнең хезмәтен кат-кат эшләтәләр, кат-кат төзәттерәләр, нәтиҗәдә, аның хезмәтләрендә Себерне яулап алуның уңай күренеш булуын әйттерүгә ирешәләр. Шунысын да әйтергә кирәк, Миллер үзенең бу хезмәтен немец телендә яза, соңыннан русчага тәрҗемә иткәндә, әсәр империя файдасына тагы да шомартыла, татар темасы шактый читкә этәрелә. Әмма, шуңа карамастан, Миллерның “Описание Сибирского царства” хезмәте ул – татар тарихы, себер татарлары турында уникаль, кабатланмас язма. Әйе, Миллер әле ул чагында ук татар тарихын өйрәнмичә Себер тарихын, шәрык тарихын белеп булмаячагын яхшы аңлаган. “Татары производят свое название от князя Татар-хана, который в седьмом колене происходил от Иафета, сына Ноя”, дип язып, Миллер татар тарихын Туфан чорларына кадәр китереп тоташтыра.

Миллер үзенең бу хезмәтендә, татарлардан тыш, башка төрки халыкларга, җирле төньяк халыклары тормышына, кытай һәм монголларның тарихына да шактый урын бирә. Ул төрки халыклар вәкиле булган якут-саха халкына зур бәя бирә, аларны кайчандыр татарлар белән бер халык булган, дип яза /180 бит/. “Якуты же среди почитаемых ими богов имеют одного, которому они присваивают имя древнего татарского князя Татара, - дип дәвам итә галим. – Этим не только подверждается родство между якутами и татарами, но этот факт можно даже принять как сильное доказательство древности татарской истории.” /Шунда ук./ Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, тува халкында “татар” сүзе бүген дә “господин”, дигәнне аңлата, бу үзе үк татар халкының борынгы заманнарда җиһангир милләт булуын раслый

торган факт.

Ерак Себернең төп халкы булган тунгус, даур һәм маньчжурларны Миллер элеккеге татарҗирләрендә яшиләр, дип яза:

“О том, что эти земли находились сначала во владении татар, свидетельствует прежде всего татарская история, а затем многочисленные находимые там остатки древностей являются также достаточным доказательством их приналежности татарам, так как тунгусы и дауры единогласно утверждают, что эти остатки не принадлежат им, и, следовательно, окончательное переселение тунгусов и дауров совершилось после победоносного завоевания татарами Китая” /182 бит/.

Миллерның бу язганнары бүгенге көн галимнәренә дә ачык җавап булып тора, чөнки Себердә нинди генә тарихи казылма тапсалар да, аны татарлар белән бәйләмәскә тырышалар.  Ә югыйсә, Идел-Уралдан Тын океанга хәтле булган барлык җирләр – борынгы татар җирләре бит, татарларның шәһәр-калалары, дәүләтләре урнашкан төп урыннар! Бу хакта тарихчы Миллер бик ачык итеп, менә нәрсә ди:

“Сколько видно в разных местах в степях остатков древних укреплений, какая масса каменных памятников, болванов, старинных могил и разных принадлежавщих им предметов встречается в этих местах! Каких только драгоценностей из золота и серебра ни было во всех этих могилах! Кому же другим могли принадлежать эти богатства, как не древним татарам, которым, как известно, достались в добычу все сокровища Китая, Персии, России, Польши, Богемии и Венгрии.” /167 бит./

Дөрес яза Герард Миллер, бөтен Себергә таралып яткан меңләгән борынгы курган-каберлекләр – алар татар халкының мирасы, аларда милләтебезнең борынгы тарихы күмелгән. Бүгенге галимнәр скиф курганнары дип өйрәнә торган бу курганнар – татарныкы, моны Миллердан кала башка немец тарихчылары да әйтер әле, анысына алга таба тукталырыбыз, иншаллах!

Миллер үзенең бу хезмәтендә Чыңгыз ханнан алып Күчем ханга кадәр булган татар дәүләтләренең тарихын киң яктырта, Себернең урыслар басып алганнан соңгы хәлләренә дә туктала. Әйткәнебезчә, бу чорда бәхәсле урыннар булса да, Миллер империя кысаларыннан торып иҗат итәргә мәҗбүр булса да, хезмәт үзенең фактик материалларга гаять бай булуы белән кыйммәтле. Татар ханнарының нәсел шәҗрәләреннән тыш, ул үзенең бу хезмәтендә урыс патшаларының грамоталарын, күп санлы архив материалларын, карталар, рәсемнәр, сүзлекләр, таблицалар, Себер җирендә урыс

шәһәрләре төзелү тарихын җентекләп язып калдыра.

Әйткәнебезчә, Герард Миллерның “Себер патшалыгы тарихы” урыс галимнәрендә  ике яклы тәэсир калдыра. Василий Татищев аңа карата уңай рецензия язса да, бу фикерне халыкка чыгармыйлар, киресенчә, Россия Фәннәр Академиясендә Миллерга каршы көчле хәрәкәт башлана. Себер тарихы кулъязмасын һәм барлык экспедиция материалларын аның кулыннан тартып алалар, аны бастырып чыгару белән башкалар идарә итә. Россия галимнәре арасында Герард Миллерга каршы иң нык эшләгән кеше ул – Михайло Ломоносов, ул калган бөтен гомерен шуңа багышлый, дисәк тә була. Ломоносов хәтта Миллерның “Происхождение имени и народа Российской” дип аталган диссертациясен дә якларга ирек бирми, 1749 елның 16 сентябрендә аны кире бордыруга ирешә. Бу хәлләрдән соң Миллер бик нык авырып китә. Шунысын да әйтергә кирәк, 1749 елда аны Россия подданствосы алырга мәҗбүр итәләр, мөгаен, диссертация яклауның таләпләре шундый булгандыр. Миллерның немец телендә язган бу диссертациясе бүгенге көнгә хәтле басылып чыкмаган, аның кайда саклануы да билгесез.

Бу хәтле килешә алмаслык антогонизмның сәбәпләре нәрсәдә соң? Беренчедән, Ломоносов Россия Фәннәр Академиясендә немецларның күплегенә һәрвакыт ризасызлык белдерә, ул урыс тарихын урыслар язарга тиеш, дип бара, Әмма ул вакытта урысларның фән тудырырлык галимнәре булмый. Икенчедән, Ломоносов урыс тарихын бик борынгы чорлардан башланган итеп күрәсе килә, әмма моңа дәлилләре булмый. Ул тартып-сузып урыс тарихын скифларга китереп чыгарып карый, әмма Геродаттан алып, Миллерга кадәр скифларның төрки халык булуларын язалар. Миллерның “Себер тарихы”  Ломоносовның бљөтен хыялларын чәлпәрәмә китерә, чөнки немец галиме бу титаник хезмәтендә Себернеђ Туфан чорларыннан татар иле булуын, борынгы скифларның да татарлар икәнлеген исбат итә. Ә Ломоносов үзенең “Древняя Российская история” хезмәтендә исә татарларны Себергә бары тик Иван Грозный чорында, ягъни, 16 гасырның икенче яртысында гына килеп урнашкан, дип яза:

“В Сибире издревле жители были чудского положения, ибо татары не так давно в ней поселились, по большей части с царем Кучумом, во времена великого государя царя Иона Васильевича.” /М.В.Ломоносов. Избранные произведения. Москва, 1986, стр.71./

Герард Миллер Россиядә тәхеткә немец хатыны Екатерина II утыргач кына бераз иркен сулыш ала, фән белән шөгыльләнүен дәвам итә. Бу елларда аның Себер тарихы, археология һәм этнография буенча күп

хезмәтләре басылып чыга, ул башка галимнәргә дә ярдәмен күрсәтә. Шунысы әһәмиятле, аларның һәрберсендә диярлек татар тарихына кагылышлы фикерләр бар, Россиядә үзенә карата басым никадәр көчле булса да, Миллер татарларга карата фикерен үзгәртми, аларны бу җирләрнең иң борынгы һәм төп халкы, дип бара.

"Страленберг к своему историко-географическому сочинению о России и Сибири приложил хорографическую карту местности близ Абаканского остога, замечательной обилием курганов, - дип яза ул. – Местность эта татарами называется Копон Карагай и некогда была очень богата по части добывания этих памятников татарской древности." /Г.Ф.Миллер. История Сибири. Москва, 1999, стр.505./

1763 елда императрицага Себер һәм Азак диңгезе буйларындагы курганнардан табылган борынгы хәзинәне бүләк итәләр, патшабикә Миллердан аның кайсы халыкныкы икәнлеген ачыкларга куша. Үзенең "Изъяснение о некоторых древностях, в могилах найденных" дигән мәкаләсендә Миллер Россиянең көньягындагы һәм төньягындагы борынгы кабер-курганнарның бер халыкныкы булырга тиешлеген әйтә. "Древние могилы, кои находят в южных странах России и Сибири, различного бывают виду, хотя большая часть оных вероятным образом происходит от одного народа, - дип яза ул. – С большею подлинностию о татарах Чингиз-хана и ближних его последователей утверждать можно, что все прочие старинные могилы как в России, так в Сибире от них происходят... Имя "Золотая орда", коим прозван главный стан владевших Россиею татарских ханов, не на ином чем, как на богатстве оных татар, основано было." /Күрсәтелгән хезмәт, 512-516-517 битләр./

Миллер Себердәге һәм Азак диңгезе буендагы борынгы курганнарны Чыңгыз хан заманы белән тәңгәлләштерсә, бүгенге галимнәрнең күпчелеге аларны скиф курганнары, дип билгели. Хәер, скифларның шул ук татарлар булуы узган гасыр тарихчылары өчен сер булмаган, бигрәк тә немец тарихчылары моның шулай икәнлегенә нык инанганнар. Әйтик, әле 1870 елда ук, немец галиме А.Д.Мордман Лейпциг шәһәрендә басылып чыккан хезмәтендә "скифларның төрки-татар телендә сөйләшүләрен" әйтә. 1904 елда немец галиме О.Франке "Скифлар алар – Урта Азия төрки-татарлары", дип язып чыга[1].

[1] Бу турыда кара: <a href=http://www.mirzayanov.com/105810721090107210881086109210861073109910741080108910901086108810801080.html>Татарофобы в истории<a/> - **В.М.**

<a href=http://www.mirzayanov.com/10581099108911031095107210831077109010801079

Шунысын да әйтергә кирәк, Себер элек чит ил галимнәре телендә "Скифия" дип тә аталган, бу хакта XIII гасыр француз тарихчысы Гильом Рубрук: "Татары поделили между собой Скифию, которая тянется от Дуная до восхода солнца", дип язып калдырган. Миллер белән бергә Себергә сәяхәт иткән немец галиме Гмелин И.Г исә:

"Вся страна слыла под именем Татария, все народы, в ней обитавшие, почитались за татар; не знали даже как далеко /на восток/ тянется суша и продолжается ли она до Америки или отделяется от нее морем", - дип язып калдыра. /Гмелин И.Г. Путешествие по Сибири. – Геттинген, 1751. Немец телендә./

Шулай итеп, дөнья галимнәре өчен Себер, Скифия, Татария сүзләре бер мәгънәне аңлаткан, алар Тын океннан Идел-Уралга кадәр җирләрнең Бөек Татар Иле булганлыгын таныганнар. Әмма Ломоносов кебек урыс галимнәре һәм бүгенге шовинист тарихчылар моның белән һич кенә дә килешергә теләмиләр, татарларны үз туган җирләрендә килмешәк итеп күрсәтү өчен тырышалар. Бүгенеге көндә Россиянең дә, урыс халкының да тарихы ялган, бу ил татар җирләре өстендә, татар тарихы хәрәбәләренә корылган, бөтен иске урыс шәһәрләре һәм кирмәннәре астында борынгы татар калалары, татар тарихы сыкрап ята... Бүгенге көндә шуны аягурә торып әйтергә тарихчы Миллерлар юк шул инде, татар җирләренең җелеген суырып ятучы "Газпром" Миллерлар гына бар...

Герард Миллер, нигездә, Себер тарихын өйрәнсә, аның милләттәше Карл Фукс Казан татарларының тормышын, этнографиясен өйрәнүгә күп гомерен багышлаган. Табип, Казан университеты профессоры һәм ректоры, җирле төбәкне өйрәнүче тарихчы һәм этнограф – ул халык күңеленә әнә шулай кереп калган. Бигрәк тә аның 1817 елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан "Краткая история города Казани" һәм 1844 елда дөнья күргән "Казанские татары, в статистическом и этнографическом отношениях" дигән хезмәте бүген дә үзенең кыйммәтен югалтмаган. Татар халкын шул кадәр белеп һәм яратып язган мондый галимнәр бүгенге көндә дә бик сирәк.

Ул чын мәгънәсендә зыялы интеллигент, гаделлек һәм тырышлык

---

10801089109010861088108010801080.html>Э. Паркер. Тысяча лет из истории татар<a/>
Монда автор кереш сүзендә "Я уже в «China Review, vol. XX
» довольно долго доказывал, что гиен-ну, скифы, гунны и тюрки были различными стадиями исторического развития одних и тех же племен; затем Шавань, Хирт и другие авторы более детально исследовали данную проблему», ди. – **В.М**.

үрнәге булып торган, Карл Фукс татарларга медицина ярдәме генә күрсәтеп калмаган, әкренләп аларның телләрен, тормышларын, тарихларын, гореф-гадәтләрен дә өйрәнә башлаган һәм нәтиҗәдә, татарлар турында уникаль хезмәтләр тудырган. Әлбәттә, аның хезмәтләре дә патша цензурасы тарафыннан каты тикшерү үткәнлеген әйтеп үтәргә кирәк, шуңа күрә Карл Фукс та, Миллер кебек, империягә кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр булган. Әмма, кайбер җитешсезлекләр булуына карамастан, Карл Фуксның татарлар турындагы хезмәтләре аннан соң килгән күп галимнәргә нигез һәм үрнәк булып тора.

"Казанские Татары, в течении трех сот лет их покорения, сохраняют еще так много собственного, национального, что заслуживает особенного внимания наблюдательного этнографа, - дип яза ул. – Они всегда живут довольно отдельно от Русских и от других их окружающих племен, перед которыми они стараются, даже и ныне, поддержать то преимущество, каким отличался никогда их предки. Они гордятся своим происхождением, своими моральными качествами, своей религей, своим домашним бытом, что все составляет их отличительный характер." /Карл Фукс. Казанские татары. Казань, 1991, стр.14./

Карл Фукс Казан татарларының тормыш-көнкүрешләрен, гадәт-холыкларын, йөз төзелешләрен, өс киемнәрен, өй эчендһге җиһазларны, ашау-эчүләрен бик җентекләп өйрәнә һәм теркәп бара, аларның урыслар кебек хәмер эчү башлауларын тәнкыйтьләп яза. Карл Фукс татарларның кунакчыллыгына таң кала, анда күп ашап, авыруга сабышырга мөмкин, чөнки егерме бишәр чәшке чәй эчерәләр, ди, татарлар ярты байлыкларын ит белән татлы ризыкка тоталар, дип яза.

"Татары горды, честолюбивы, гостепреимны, сребролюбивы, чистоплотны, по их состоянию довольно просвещенны, почти несуеверны, рождены для торговли, хвастливы, между собой дружелюбны, искательны, вкрадчивого свойства. Во всем умерены и довольно трудолюбивы", - дип тасвирлый ул татар халкының холкын һәм, әйтергә кирәк, шактый дөрес тасвирлый. /Күрсәтелгән хезмәт, 34 бит./ Милләтебезгә бүген дә шушы асыл сыйфатларга әйләнеп кайтырга һәм башка халыкларга үрнәк булып яшәргә кирәк.

Карл Фукс татарларның йөз төзелешләрен дә, тән тљзелешләрен дә бик яратып тасвирлый, аларда бөек халыкның чагылышларын күрә. "Вообще Казанские Татары прекрасного телосложения, - дип яза ул. – Лицо у них длиноватое, глаза большие серые или черные, взор их проницателен; нос длинный, с горбом, восточный... Плечи преширокие,

грудь высокая... Они вообще высокорослы, и стань их необыкновенно прям. Походка их очень важная. Тело у них вообще белое и без волос.” /Күрсәтелгән хезмәт, 32 бит./ Әйе, без монда урыслар яратып тасвирлаган мескен “чаплашка” татарны түгел, ә бөркет карашлы, карчыга борынлы, баһадир бәдәнле, төз гәүдәле ак татарны күрәбез. Галим татарларның аяк атлап йөрешләренә хәтле күзәткән һәм “походка их очень важная”, дип нәтиҗә ясаган. Бу исә үз бәясен белеп яшәгән кешегә карата гына әйтелә ала, ягъни, татарлар үзләренең кемлекләрен беркайчан да онытмаганнар һәм бу хәл аларның аяк атлауларында хәтле чагылган!

Карл Фукс шулай ук татарларның чисталыкларына таң кала, аларның өйдә нинди тынычлыкта һәм гармониядә яшәүләрен сокланып яза. “Домашний татарский быт мне очень нравится, особенно тишина и мир между женщинами, которых в большом семействе бывает до десяти, и иногда три жены у одного мужа, - дип дәвам итә ул. - Восточные законы наложили на них очень искусно печать кротости. Татары живут очень опрятно. В их избах чисто: они имеют страсть несколько раз в год белит печь, что делают даже и в развалившихся хижинах.” /Күрсәтелгән хезмәт, 40 бит./

Әлбәттә, татарларны шул хәтле олылап язганнан соң, Карл Фуксның милләтебезгә карата кайбер сүзләрен кабул итәсе килми, әйтерсең лә аларны гуманист-галим түгел, цензор кулы өстәп куйган. Әйтик, аның бу хезмәтендә татарлар турында рәхимсез, тупас һәм карак дигән гаепләүләр бар, моның Карл Фукс сүзләре икәнлегенә берничек тә ышанып булмый! Ул язманың канвасына, стиленә, идеясенә туры килми, татарлар белән дус яшәгән интеллигент кешенең милләтнең күзенә карап мондый гаепләүләр әйтүе һич мөмкин түгел! Татар халкын немец галименә карата нәфрәтләндерү өчен моны соңыннан шовинистик карашлы цензорлар өстәгән булырга тиеш.

Татарлардан тыш, Карл Фукс чуваш, мордва, башкортлар турында да бай мәгълүмат туплаган, бу халыкларның җырларын, бәетләрен җыйган, китапта аларның үрнәкләрен биргән, ул шулай ук җирле халыкларның этнографиясен өйрәнгән, милли һәм дини бәйрәмнәренә киң тукталган. Ә галимнең “Краткая история города Казани” хезмәте ул Казан тарихына гына түгел, бөтен татар тарихына карый. Биредә халкыбызның Болгар чоры да, Казан ханлыгы тарихы да, татар ханнары язмышы да, Казан алынганнан соң булган хәлләр дә шактый киң яктыртылган. Әмма монда галимнең нигездә урыс елъязмаларына гына таянып эш иткәнлеге күренеп тора, шуңа күрә ул тарихи фактларны алар күзлегеннән чыгып тасвирларга мәҗбүр була, хезмәт

патша цензурасы тарафыннан шактый кыскартылган һәм таланган булырга охшый. Шуңа карамастан, Карл Фуксның бу хезмәте татар тарихына объектив бәя бирергә омтылуы белән аерылып тора.

Карл Фукс Казанда күмелгән, бүгенге көндә биредә аның һәйкәле, аның исемендәге бакча бар. Әмма галимнең үзе исән чакта ук салып калдырган иң зур һәйкәле – аның хезмәтләре. Аны татары да, урысы да, яратып, "Безнең Фукс", дип атап йөрткәннәр, һәм бу немец кешесе бүген дә күпләр өчен "Безнең Фукс" булып кала бирә.

Язмабызда күренекле немец галиме Фридрих Вильгельм - Василий Васильевич Радлов турында киңрәк мәгълүмат бирмәсәк, һич тә дөрес булмас иде. Шушы көннәрдә 170 еллык юбилее билгеләнеп үтелгән бу бөек шәрыкчы-востоковедның немец милләтеннән булуын хәзер инде күпләр белмидер дә. Ә бит ул – Россия тюркологиясенә нигез салучыларның берсе, төрки халыкларның телен, тарихын, авыз иҗатын, мәдәниятен өйрәнүче һәм шулар буенча тиңсез фәнни хезмәтләр язып калдыручы зур галим! Ул Берлин университетының философия факультетын тәмамлаган, Европа телләре белән беррәттән, татар, төрек,гарәп, фарсы, кытай, монгол телләрен яхшы белүче галим, Миллер кебек, Россиядә үзенең фәнни эшчәнлеген җирле халыкларның тарихын һәм тормышын өйрәнүдән башлый.

Аның 1859-1871 елларда Алтай һәм Себердә җирле алтай, хакас, казах, якут, шор, тофалар һәм себер татарларыннан җыйган этнографик материаллары, халык авыз иҗаты үрнәкләре бүген дә бәяләп бетергесез кыйммәтле хәзинә. Бүгенге көндә том-том басылып чыккан татар дастаннары өчен дә без Радловка рәхмәтле булырга тиешбез, чөнки аларда, нигездә, немец галиме җыеп калдырган борынгы ядкәрләр урын алган. Радловның "Төрки кабиләләрнең халык әдәбияте үрнәкләре" дигән хезмәте дә бүген алышытыргысыз фәнни хезмәт булып тора, чөнки ул халыкларның инде күпчелеге юк, ә Радлов җыеп калдырган авыз иҗаты, фольклор яши...

Радловның Казан чоры да искиткеч нәтиҗәле һәм бай. Биредә ул 1871 елдан 1884кә хәтле яши, Казан уку-укыту округының татар-башкорт, казах мәктәпләре инспекторы булып эшли, татар халкы белән якыннан танышып, аның өчен дәреслекләр, фәнни китаплар язып бастыра. Биредә ул татар теле үрнәкләре кергән "Белек" дип аталган хрестоматия, "Халык әдәбияте үрнәкләре", "Төрки телләрнең чагыштырма фонетикасы", "Aus Sibirien" дип аталган Себер энциклопедиясен һәм башка хезмәтләрен бастырып чыгара. Шулай ук Радловныћ татар зыялылары белән тыгыз элемтәдә торуын, бигрәк тә фольклорчы-галим Каюм Насыйри хезмәтләре белән якыннан таныш

булуын әйтергә кирәк.

Василий Радлов гомеренең соңгы елларын Петербург шәһәрендә уздыра, ул тагы 35 елга якын Россия тюркологиясенә хезмәт итә. Ул – төрки телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнүгә нигез салучы, төрки телләрнең классификациясен эшләүче һәм данлыклы Орхон-Енисей рун язмаларын укып бирүче булып та тора. Филология фәннәре докторы Вахит Хаков язуынча: “Үзенең фәнни эшчәнлегендә В.Радлов тюркологиянең күп төрле өлкәләрен колачлый: диалектография һәм диалектология, лексикография һәм лексикология, төрки телләрнең тарихи чагыштырма фонетикасы һәм грамматикасы, төрки текстология, рун, уйгыр һәм гарәп алфавиты белән язылган төрки язма ядкәрләр, төрки фольклор, төрки этнография һәм археология.” /”Мәдәни җомга” газетасы, 2007 ел, 26 гыйнвар саны.

Гаҗәп хәл бит – татарларга Россия университетларында уку тыелган заманда, татар тарихы төрле яктан таланган һәм милләт империя тарафыннан кимсетелгән бер чорда, халкыбызга ярдәмгә немец галимнәре килә! Алар татар халкының тарихын һәм этнографиясен барлыйлар, авыз иҗатын туплыйлар, телен өйрәнәләр, заманында зур дәүләтләр тоткан милләтебез турында титаник хезмәтләр язып калдыралар. Без, бүгенге тарихчылар һәм татар зыялылары, хәзер дә бу хезмәтләргә таянабыз, аларда бөек тарихыбызны һәм аянычлы язмышыбызны күреп, тетрәнәбез, борынгы халык җәүһәрләрен укып, ләззәтләнәбез. Һәм рәхмәт әйтәбез! Бөек немец халкының бөек улларына татар халкын күтәргән һәм аның турында дөреслекне язып калдырганнары өчен, милләтебез исеменнән чиксез рәхмәтләребезне җиткерәбез! Бу тарихи һәм мәдәни багланышлар бүген дә дәвам итсен иде, дигән изге теләкләрдә калабыз.

**Фәүзия Бәйрәмова,**
***язучы, тарих фәннәре кандидаты.***